Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Юлсубино авыл
җирлеге Советы

**8 номерлы КАРАР**

Юлсубино авылы 2019 елның 13 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2014 елның 06 октябрендә кабул ителгән «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында 15.04.2019 ел, №63-ФЗ «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Юлсубино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2014 елның 06 октябрендә кабул ителгән «Физик затлар милкенә салым турында» гы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябре 12 номерлы, 2015 елның 29 маенда 15 номерлы, карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 3.2 пунктының 12 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2) 3.2 пунктның 11 абзацында «1 ноябрьгә кадәр» сүзләрен «31 декабрьдән дә соңга калмыйча»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Карарны дәүләт теркәвеннән соң http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов